| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.08.2025 № 879/1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2028 елларга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 16 февралендәге 188 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 06 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2028 елларга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 16 февралендәге 188 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17 ноябрендәге 1488 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законын, «Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясен раслау турында» Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 28 декабрендәге 1124 номерлы Указы нигезендә һәм 2024-2028 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы торуның комплекслы планын (№пр-2610 от 30.12.2023 ел) гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:».

2. Күрсәтелгән карар белән расланган «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» программасы паспортына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны эшләү нигезләре | РФ Президентының «Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясен раслау турында»28.12.2024 № 1124 Указы;<br>«Террорчылыкка каршы тору турында» 06.03.2006 N 35-ФЗ Федераль законы;<br>Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия рәисенең 25.08.2018 № ПР-212 Карары белән расланган» Татарстан Республикасы муниципаль районында |

| | |
|---|---|
| | террорчылыкка каршы комиссия турында нигезләмә";<br>2024-2028 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы торуның комплекслы планы № пр-2610 от 30.12.2023.». |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин